ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.02.2019 п.г.т.Алексеевское № 63

**“Алексеевск муниципаль районы
башкарма комитетыархив бүлегенең
дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү
административ регламентларын раславы
турында”гы Алексеевск муниципаль районы
башкарма комитетының 23октябрь, 2018 ел,
367нчекарарынаүзгәрешләркертүтурында**

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә Федераль закон таләпләренә туры китерү максатында “ Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты архив бүлегенең дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентларын раславы турында”гы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 23 октябрь, 2018 ел, 367 нче карарына үзгәрешләр кертергә

**карар бирәм:**

1. 1-8 нче кушымталарны түбәндәге нигезләмәләр белән тулыландырырга:

“Гариза бирүчегә җавапта канәгатьләндерелергә тиешле шикаятьне таныган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күп функцияле үзәк яки оешма тарафыннан тормышка ашырган гамәлләр турында дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган бозуларны ашыгыч төстә бетерү максатында 210-ФЗ Федераль законның 16 нчы маддәсе 1.1 өлешендә каралган мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлык өчен гафу үтенелә һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр алу максатында гариза бирүчегә алга таба үтәргә кирәк булган гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Канәгатьләндерелергә тиешле булмаган шикаятьне таныган очракта гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләп аңлатыла, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять итү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

2.1-5 нче кушымтаның 5.1 нче пункты3 нче абзацын һәм 6-8 нче кушымтаның 5.1 нче пунктын түбәндәге норма белән тулыландырырга:

“дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул иткәндә беренче тапкыр кабул итүдән баш тартканда күрсәтелмәгәндәүләт һәм муниципаль хезмәтләр документлар биргәндә яки мәгълүматлар тапшырганда аларның булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгәндәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә 210 нчы Федераль законның 7 нче маддәсе 1 нче өлеше 4 нче пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт яки муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен яисәдәүләт яки муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә кирәкле документларны кабул иткәндә аларны беренче тапкыр кабул итүдән баш тартканда документлар һәм мәгълүматларның булмавы яки дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүматларгагариза бирүченең таләбе”. Күрсәтелгән очракта, әгәр күп функцияле үзәккә, аның карарларына һәм эшләренә шикаять бирелсә, 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 нчы маддәсе 1.3 нче өлешендә билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү вазыйфасы йөкләнсә,гариза бирүченең күп функцияле үзәк,күп функцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эш-гамәлләренә (эшсезлегенә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирүе мөмкин.

3. 1-5 нче кушымтаның 5.1 нче пункты 7 нче абзацы, 6-8 нче кушымтаның 5.1 нче пункты 3 нче пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«документлар яки мәгълүматлар бирү яисә эш-гамәлләрне тормышка ашыруга (дәүләт яки муниципаль хезмәтләр бирү өченРоссия Федерациясенең норматив хокук актларында,Россия Федерациясе субъектларының норматив хокук актларында, муниципаль хокук актларында аларны бирү яки гамәлгә ашыру каралмаганда) гариза бирүченең таләбе”.

4. 6-8 нче кушымтаның 5.3 нче пункты 1 һәм 2 абзацларын яңа редакциядә игълан итәргә:

“Гариза кәгазьдә язма формада, электрон формада дәүләт хезмәтен тәкъдим итүче органга бирелә яки 1-6-8 нче кушымтаның 5.3 пункты 1 һәм 2 нче н яңа редакциядә бәян итәргә:

“Гариза кәгазьдә язмача, электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүче органга яки күп функцияле үзәккәяисә оештыручысы күп функцияле үзәк булган (моннан ары – күп функцияле үзәкне оештыручы) дәүләт хакимиятенең тиешле органына (җирле үзидарә органына), шулай ук 210-ФЗ Федераль законның 16 нчы маддәсе 1.1 өлешендә каралган оешмаларга бирелә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче яки муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе карарларына һәм эш-гамәлләренә (эшсезлегенә) шикаятьләр югарыгы органга (ул булганда) бирелә яки ул булмаганда турыдан-туры, ягънидәүләт хезмәте күрсәтүче, йә муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала.

Күп функцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм эш-гамәлләренә (эшсезлегенә) шикаятьләр әлеге күп функцияле үзәк җитәкчесенә бирелә.Күп функцияле үзәк карарларына һәм эш-гамәлләренә (эшсезлегенә) шикаятьләркүп функцияле үзәкне оештыручыга яки Россия Федерациясе

субъектының норматив хокук акты тарафыннан вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи затка бирелә. Оешмалар хезмәткәрләренең 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 нчы маддәсе 1.1 өлешендә каралган карарларына һәм эш-гамәлләренә (эшсезлегенә) шикаятьләр әлеге оешмаларның җитәкчеләренә бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрнең, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесенең яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органның карарларына һәм эш-гамәлләренә (эшсезлегенә) шикаятьләр почта, күп функцияле үзәк аша,"Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрен, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайтын, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталын файдаланып җибәрелә, шулай ук гариза бирүче шәхси кабул ителгәндә бирелә.Оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 нчы маддәсе 1.1 өлешендә каралган карарларына һәм эш-гамәлләренә (эшсезлегенә) шикаятьләрпочта аша, Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрен, әлеге оешмаларның рәсми сайтын, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталын файдаланып җибәрелә, шулай ук гариза бирүче шәхси кабул ителгәндә бирелә.

1. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырырга һәмАлексеевск муниципаль районының “Интернет”мәгълүмати-телекоммуникацион рәсми сайтында урнаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты архив бүлеге начальнигы Л.Г. Козонковага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**